**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**НОРЛАТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ**
**КАРАР**

02.06.2015г № 225

Норлат авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 ноябрендә кабул ителгән 187 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым салу турында» карарына үзгәрешләр кертү турында.

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Норлат авыл җирлеге Советы

**карар итте:**

1. Норлат авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 ноябрендәге 187 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым салу турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1) 2 нче пунктта:

1.1) 1 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"мәйданы 30 квадрат метрдан артмаган һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнгән исемлеккә кертелгән салым салу объектында урнашкан салым түләүченең теләге буенча бер гараж яисә машина урынына; Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 10 пунктындагы икенче абзацында каралган салым салу объектына карата»;

1.2) 4 пунктчада:

1.2.1) беренче абзацта "2 процент" сүзләренә карата: "2015 елда-1,5 процент, 2016 елда-1,8 процент, 2017 елдан-2 процент" сүзләренә алмаштырырга».;

1.2.2) дүртенче абзацны төшереп калдырырга;

1.3) 4 пункттан соң түбәндәге эчтәлекле 4.1 пунктчага өстәргә:

"4.1) һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата 2 процент;»;

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны «Яшел Үзән» газетасында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru( Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталына Интернет челтәрендә) http://zelenodolsk.tatarstan.ru урнаштырырга.

Норлат
авыл җирлеге башлыгы
Совет рәисе И. Ф. Багаутдинов